**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**№ 13/1** «25» май 2021 ел

**Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советының 2020 елның 1 декабрендәге «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге бюджеты турында» 7/1 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, «Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 декабрендәге «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге бюджеты турында» 7/1 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» мәгълүматны тыңлаганнан соң

**КАРАР БИРДЕ :**

1. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 декабрендәге «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге бюджеты турында» 7/1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 статья 1 пункт 1 пунктчада «9847,31» саннарын «12164,32» саннарына алыштырырга;
- 1 статья 1 пункт 2 пунктчада «9847,31» саннарын «12167,81» саннарына алыштырырга;
- 1 статья 1 пункт 3 пунктчада «0» санын «3,49» саннарына алыштырырга.

2. 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Мәләкәс авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2021 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлегенең муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел, мондый карарлар җирле үзидарә органнарына, муниципаль казна учреждениеләренә яңа функцияләр һәм вәкаләтләр бирү белән бәйле рәвештә кабул ителү очракларыннан тыш».

3. 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Мәләкәс авыл җирлеге бюджетының 2021 елның 1 гыйнварена калган акчалары, Мәләкәс авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен 2020 елда шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә тотылган өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә, 2021 елда, Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, әлеге максатларга бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә».

4. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 декабрендәге «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге бюджеты турында» 7/1 номерлы карарына 1, 3, 5, 7, 9, 11 кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә.

5. Әлеге карарны Мәләкәс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми игълан ителгән мизгелдән үз көченә керә.

Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Ю.П. Васильев